РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

№31/6

6 февраль 2019 ел Чистай шәһәре

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советы депутаты
статусы хакындагы Нигезләмәне
раслау турында

Чистай шәһәр прокурорының Чистай шәһәр Советының 2006 елның 6 апрелендә кабул ителгән “Чистай шәһәр Советы депутаты статусы хакында”гы Нигезләмәне раслау турында”гы 8/1нче карарына протестын карап, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче Федераль законы, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45нче законы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы депутаты статусы турында тәкъдим ителә торган Нигезләмәне расларга.

2.Көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2006 елның 6 апрелендә кабул ителгән “Чистай шәһәр Советы депутаты статусы хакында”гы Нигезләмәне раслау турында”гы 8/1нче карары;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2010 елның 14 сентябрендә кабул ителгән “Чистай шәһәр

Советының 2006 елның 6 апрелендә кабул ителгән “Чистай шәһәр Советы депутаты статусы хакында”гы Нигезләмә турында”гы 8/1нче карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 40/5 нче карары;

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2016 елның 12 апрелендә кабул ителгән “Чистай шәһәр Советының 2006 елның 6 апрелендә кабул ителгән “Чистай шәһәр Советы депутаты статусы хакында”гы Нигезләмә турында”гы 8/1нче карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 5/6 нчы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтындагы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә: http://chistopol.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталын”да “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә (Добронравова О.В.) йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов